КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 6 март г.Казань № 178

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 февраль, 128 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 860 нчы; 2015 ел, 26 август, 623 нче; 2016 ел, 17 октябрь, 749 нчы; 2016 ел, 31 октябрь, 800 нче; 2017 ел, 10 май, 269 нчы; 2018 ел, 30 июль, 613 нче; 2018 ел, 7 ноябрь, 983 нче; 2018 ел, 19 декабрь, 1179 нчы; 2018 ел, 29 декабрь, 1302 нче; 2019 ел, 13 июль, 577 нче; 2019 ел, 19 ноябрь, 1057 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 нче пунктның егерменче абзацында «Татарстан Республикасының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән» сүзләренә алыштырырга;

3.3 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.3.56 нчы пунктча өстәргә:

«3.3.56. Ведомство буйсынуындагы оешмаларда хезмәт законнарының һәм хезмәт хокукы нормаларын үз эченә алган башка норматив хокукый актларның үтәлешенә ведомство контролен гамәлгә ашыру.»;

4.4 нче пунктның тугызынчы һәм унынчы абзацларына «I, II һәм VI типтагы мополисахаридоз» сүзләреннән соң «ачыкланмаган апластик анемия, II (фибриноген), VII (лабиль), X (Стюарт-Прауэр) факторларның нәселдән килгән кытлыгы,» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин